**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 16 июль | № 521

г. Казань

«Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларның эш нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы (алга таба – конкурс) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

Конкурс турындагы нигезләмә нигезендә конкурсны үткәрүне оештыруны тәэмин итәргә;

әлеге карарны кабул иткән көннән бер ай эчендә түбәндәгеләрне расларга:

конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне;

конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан конкурста катнашу өчен тапшырылган материалларда чагылган мәгълүматларны карауны һәм тикшерүне гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\521.doc